| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 Казан шәһәре № 3-19/э

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-15/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә озак сроклы хосусый тарифларны һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемен 2020 ел өчен үзгәртү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә хосусый тарифлар билгеләү турында» 10.12.2015 № 3-15/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2016 № 3-10/э, 08.12.2017 № 3-10/э, 12.12.2018 № 3-9/э карарлары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-15/э карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2019 № 3-19/э карары редакциясендә)

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2016 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән хосусый тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2016 | 818 122,36 | 20,58 | 1,92403 | 818 122,36 | 20,08 | 1,92535 |
| | | 2017 | 797 502,20 | 20,40 | 1,87587 | 797 502,20 | 21,83 | 1,87730 |
| | | 2018 | 835 828,71 | 24,40 | 1,94366 | 835 828,71 | 25,37 | 1,94463 |
| | | 2019 | 866 450,41 | 25,43 | 2,01500 | 866 450,41 | 27,18 | 2,01675 |
| | | 2020 | 770 920,66 | 27,21 | 1,79742 | 770 920,66 | 27,21 | 1,79742 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2015 № 3-15/э карарына 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.12.2019 № 3-19/э карары редакциясендә)

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2016-2020 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы | 2016 | 67 347,83 |
| | | 2017 | 65 650,38 |
| | | 2018 | 68 805,42 |
| | | 2019 | 71 326,20 |
| | | 2020 | 63 462,19 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге